КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 7 декабрь г.Казань № 1184

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәдәният оешмалары хезмәтләрен тәэмин итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанс ягыннан тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында» 2019 ел, 30 декабрь, 1237 нче карары белән расланган Мәдәният оешмалары хезмәтләрен тәэмин итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанс ягыннан тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү һәм бүлү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәдәният оешмалары хезмәтләрен тәэмин итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанс ягыннан тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара

трансфертлар бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында» 2019 ел, 30 декабрь, 1237 нче карары белән расланган Мәдәният оешмалары хезмәтләрен тәэмин итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанс ягыннан тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү һәм бүлү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктның өченче абзацында «33 мең кеше» сүзләрен «50 мең кеше» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктта «форма» сүзен «бертип форма» сүзләренә алмаштырырга;

13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына килешүдә билгеләнгән срокларда муниципаль берәмлекләрнең финанс органнары өчен Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган муниципаль берәмлекләр бюджетларының бердәм счетларына күчерелә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин